**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 15 май № 287

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 25 октябрь, 794 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 25 октябрь, 794 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 май, 366 нчы; 2015 ел, 1 апрель, 204 нче, 2015 ел, 7 ноябрь, 840 нчы һәм 2015 ел, 7 декабрь, 923 нче һәм 2016 ел, 19 май, 322 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

программа паспортында:

«Программаны тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)» бүлегендә:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы телләре турында законнарны һәм Программаны тормышка ашыру мәсьәләләре функцияләренә караган дәүләт хакимияте органнары

һәм җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре саны 45 берәмлеккә җиткереләчәк;»

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төзелгән һәм гамәлгә кертелгән Казан (Идел буе) федераль университетының Каюм Насыйри институты филиаллары – укыту-мәдәни татар үзәкләре саны 11 берәмлеккә җиткереләчәк;»;

II бүлекнең «Программаның индикаторлары» бүлекчәсендә:

«Татарстан Республикасы телләре турында законнарны һәм Программаны тормышка ашыру мәсьәләләре функцияләренә караган дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре саны, берәмлек» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы телләре турында законнарны һәм Программаны тормышка ашыру мәсьәләләре функцияләренә караган дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнарының структур бүлекчәләре саны, берәмлек | 3 | 44 | 45 | 45 | 45 | 45 | 45 | 45»; |

«Төзелгән һәм гамәлгә кертелгән Казан (Идел буе) федераль университетының Каюм Насыйри институты филиаллары – укыту-мәдәни татар үзәкләре саны, берәмлек» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Төзелгән һәм гамәлгә кертелгән Казан (Идел буе) федераль университетының Каюм Насыйри институты филиаллары – укыту-мәдәни татар үзәкләре саны, берәмлек | 0 | 2 | 3 | 2 | 1 | 1 | 1 | 1»; |

Программага 1 нче, 2 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (теркәләләр).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\287.docx